# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«1998 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

1 статья. "1998 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 1997, № 12) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле икенче һәм өченче өлешләр өстәргә:

"1998 елда промышленность предприятиеләре Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелә торган өлешендә 1998 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын төзегәндә исәпкә алынган фараз күрсәткечләреннән тыш җитештерелгән һәм сатылган продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) күләменә табышка салым түләүдән азат ителәләр, дип билгеләргә.

Дәүләт хакимиятенең җирле органнарына җирле бюджетларга кертелә торган табышка салым өлешенә карата шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә".

2. Түбәндәге эчтәлекле $12^1$ статьясы өстәргә: "$12^1$ статья. Агымдагы салымнарны вакытында түләүче промышленность предприятиеләре һәм башка товар җитештерүчеләр 1998 елда Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелә торган өлешенә өстәлгән бәягә салым түләүдән, автомобиль юлларыннан файдаланучыларга, ягулык-майлау материаллары сатуга салымнардан һәм Татарстан Республикасының республика бюджетын төзегәндә исәпкә алынган фараз күрсәткечләреннән тыш җитештерелгән һәм сатылган продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) күләменә

Гомумтармак, тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фондына түләүләрдән азат ителәләр, дип билгеләргә.

Предприятиеләр һәм оешмалар өстенлекле ташламалар бирүгә бәйле янга кала торган акчаларны билгеләнгән тәртиптә расланган бизнеспланнарда каралган гамәлләрне финанслау өчен җибәрәләр».

3. 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"17 статья. Татарстан Республикасының республика бюджетына салымнар түләү һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча салым түләүчеләр өчен кичектерүләр һәм (яисә) өлешләп түләүләр вакыты агымдагы ел беткәнче бирелергә мөмкин, әмма ул вакыт түбәндәге нигезләрдә алты айдан артмаска тиеш, дип билгеләргә:

үтәлгән дәүләт оборона заказын Татарстан Республикасының республика бюджетыннан яисә федераль бюджеттан финанслау тоткарланган очракта - кичектерелгән бурыч суммасына процентлар исәпләмичә;

бер мәртәбә салым түләгәндә яисә салымнарны һәм тиешле пеняларны түләү буенча куелган таләпләрне үтәгәндә банкротлык куркынычы янаган очракта - бюджет акчаларыннан файдаланган өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының икедән бере күләмендә процентлар рәвешендә түләү алып;

табигый бәла-казалар, технологик афәтләр йә гадәттән тыш башка шартлар яисә шул шартлардагы аяныч хәлләр нәтиҗәсендә шактый матди зыян китерелгән очракта - бюджет акчаларыннан файдаланган өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының өчтән бере күләмендә процентлар рәвешендә түләү алып".

4. Түбәндәге эчтәлекле $17^1$ статьясы өстәргә: "$17^1$ статья.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты салымнар, җыемнар һәм исәпләнгән пенялар буенча, шулай ук салым законнарын бозган өчен штрафлар буенча юридик затларның 1998 елның 1 гыйнварена Татарстан Республикасының республика бюджетына булган бурычларын, күрсәтелгән бурычларны түләү өчен салымнар һәм җыемнар буенча - дүрт елга кадәр, пенялар һәм

штрафлар буенча ун елга кадәр юридик затларга кичектерү һәм (яисә) аларны өлешләп түләү билгеләп, 1998 елда кабат структуралаштырырга тиеш.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән шартларда юридик затның гамәлгә куючылары, катнашучылары яисә мөлкәт милекчеләре тарафыннан аның Татарстан Республикасының республика бюджетына булган барлык бурычын каплау өчен җитәрлек тәэмин ителеше тәкъдим ителгәндә генә, шулай ук кичектерүнең һәм яисә өлешләп түләүнең барлык чорында агымдагы түләүләр үз вакытында һәм тулысынча түләнгәндә генә, юридик затларга бурыч түләү буенча кичектерү һәм (яисә) аны өлешләп түләү билгеләнә.

Түләүләрне кичектергән һәм (яисә) сумманы өлешләп түләгән өчен процентлар алына, аларның күләме, Россия Федерациясе Үзәк банкының шушы процентларны түләгән көндә гамәлдә булган рефинанслау ставкасының дүрттән берен тәшкил итә.

Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм максатчыл бюджет фондларына мәҗбүри түләүләр буенча, шулай ук күрсәтелгән мәҗбүри түләүләрне вакытында түләмәгән өчен пенялар һәм штрафлар буенча бурычлары булган предприятиеләрдән һәм оешмалардан - 1994-1997 елларда дәүләт оборона заказын үтәүчеләрдән - дәүләт оборона заказы (эшләре) өчен, шулай ук куәтләрне мобилизацияләүгә ярдәм итү буенча төзелгән дәүләт контрактлары (шартнамәләре) нигезендә башкарылган эшләр өчен вакытында түләмәүгә бәйле рәвештә 1998 елның 1 гыйнварена барлыкка килгән бурыч, исәпләнгән пенялар һәм штрафлар тиешле елларда продукция җитештерүнең (эшләр башкаруның) гомуми күләмендә күрсәтелгән заказның ел саен билгеләнә торган күләмнәренең чагыштырма күләменә пропорциональ өлешендә юкка чыгарыла, дип билгеләргә. Дәүләт заказчылары тарафыннан дәүләт оборона заказы (эшләре) буенча бурыч барлыгы раслaнганда, салым органнары һәм максатчыл бюджет фондлары күрсәтелгән пеняларның һәм штрафларның суммасын юкка чыгаруны башкарырга тиешләр.

Бурычның продукция (эшләр) өчен вакытында түләмәү аркасында барлыкка килүен дәүләт заказчылары раслаганда,

предприятиеләрнең һәм оешмаларның - дәүләт оборона заказын (эшләрен) үтәүчеләрнең - Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм максатчыл бюджет фондларына дәүләт контрактлары (шартнамәләре) буенча түләүгә сәләтсез булулары нәтиҗәсендә кичектерелгән түләүләре өчен 1998 елда пенялар исәпләмәскә.

Дәүләт хакимиятенең җирле органнарына җирле бюджетларга кертелә торган акчалар өлешенә карата шундый ук карарлар кабул итәргә тәкъдим итәргә".

2 статья. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 10 июле
№ 1735